| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.03.2023 Казан ш № 170

Баланың тууы һәм аны тәрбияләүгә бәйле рәвештә айлык пособие бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Б о е р ы к б и р ә м:

Баланың тууы һәм аны тәрбияләүгә бәйле рәвештә айлык пособие бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 15.03.2023 № 170 боерыгы белән расланды

# Баланың тууы һәм аны тәрбияләүгә бәйле рәвештә айлык пособие бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## I. Гомуми нигезләмәләр

### Административ регламентны җайга салу предметы

1. Әлеге Административ регламент Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының административ процедуралары һәм гамәлләре вакытын һәм эзлеклелеген билгели, аңа «Балалы гражданнарга дәүләт пособиеләре турында» 1995 елның 19 маендагы 81-ФЗ номерлы федераль законның $4^1$ статьясы нигезендә бала туу һәм тәрбияләүгә бәйле рәвештә айлык пособиене гамәлгә ашыруга вәкаләтләр тапшырылган (алга таба, тиешенчә – вәкаләтле орган, айлык түләү, дәүләт хезмәте).

### Гариза бирүчеләр даирәсе

2. Дәүләт хезмәте Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнары булган түбәндәге затларга (алга таба – мөрәҗәгать итүче) күрсәтелә:

әгәр йөкле хатынның йөклелек вакыты алты һәм аннан да күбрәк атна тәшкил итсә һәм ул йөклелекнең башлангыч чорында (12 атнага кадәр) медицина оешмасында исәпкә алынган булса;

Россия Федерациясе гражданины булган һәм Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче 17 яшькә кадәрге баланың әти-әнисенең (уллыкка алучыларның, опекуннарының (попечительләренең) берсенә.

әгәр әлеге пособиене билгеләү өчен мөрәҗәгать итү көненә «Россия Федерациясендә яшәү минимумы турында» 1997 елның 24 октябрендәге 134-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә гаиләнең җан башына уртача керем күләме яшәү (тору) урыны буенча яисә хакыйкый яшәү урыны буенча Россия Федерациясе субъектында билгеләнгән җан башына яшәү минимумы күләменнән артмаса, баланың тууы һәм аны тәрбияләүгә бәйле рәвештә айлык пособие хокукы барлыкка килә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән үзенең вәкаләтле вәкиле (алга таба – вәкил) аша файдалана ала.

Шул ук вакытта мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтеннән файдалану алу буенча хокукый мөнәсәбәтләрдә катнашуы аны вәкилле булу хокукыннан мәхрүм итми, шулай ук вәкилнең катнашуы да мөрәҗәгать итүчене әлеге хокукый мөнсәбәтләрдә шәхсән катнашу хокукыннан мәхрүм итми.

**Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат бирү тәртибенә карата таләпләр**

3. Мөрәҗәгать итүчеләргә дәүләт хезмәте күрсәтү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирү түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

мөрәҗәгать итүче (вәкил) турыдан-туры мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтле органның вазыйфаи заты (алга таба – вазыйфаи зат) тарафыннан;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба-күпфункцияле үзәк) хезмәткәре тарафыннан;

телефон, факсимиль һәм башка телекоммуникация элемтәсе чаралары аша;

дәүләт хезмәте күрсәтү урыннарында мәгълүмат стендларын рәсмиләштерү юлы белән, аларда әлеге Административ регламентның 39 пунктындагы икенче һәм тугызынчы абзацларында күрсәтелгән мәгълүмат урнаштырыла;

мәгълүмат материалларын массакүләм мәгълүмат чараларында басытырып, мәгълүмат брошюралары, буклетлар, бүтән төрле басма продукция чыгару юлы белән;

мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта (алга таба – сайт, «Интернет» челтәре), «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Бердәм портал) урнаштыру юлы белән;

брошюралар, буклетлар һәм башка мәгълүмат материалларын гражданнарны кабул итү өчен билгеләнгән биналарда, шулай ук әлеге оешмалар белән килешенеп, барлык милек формасындагы бүтән оешмаларга, шул исәптән күп функцияле үзәкләрдә урнаштыру юлы белән;

мөрәҗәгать итүчеләрнең язмача мөрәҗәгатьләренә җаваплар аша.

4. Телефон аша дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат биргәндә, телефон аша мөрәҗәгатьне кабул итеп, вазыйфаи зат үзе белән таныштырырга: фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта), вазыйфасын, вәкаләтле органның исемен әйтергә тиеш.

Вазыйфаи зат гражданнарны кабул итү графигын, төгәл почта адресын, килү ысулын, ә кирәк булганда – язмача мөрәҗәгатькә карата таләпләр турында хәбәр итәргә тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында телефон аша мәгълүмат бирү эш графигы нигезендә башкарыла.

Телефон һәм башка телекоммуникация чаралары аша мөрәҗәгать итүчегә аның шәхси мәгълүматына кагылышлы мәгълүмат биргәндә, вазыйфаи зат мөрәҗәгать итүче әйткән фамилиясенең, исеменең, атасының (булган очракта) исемен; шәхесне таныклый торган документ белешмәләренең; контроль мәгълүматның төгәллеген тикшерү юлы белән, мөрәҗәгать итүченең шәхесен тәңгәлләштерә.

Сөйләшү вакытында вазыйфаи зат сүзләрне төгәл әйтергә һәм башка мөрәҗәгать килү сәбәпле сөйләшүне өзмәскә тиеш.

Мөрәҗәгать итүче куйган сорауларга җавап бирү мөмкинлеге булмаса,

телефон аша мөрәҗәгать итүче башка вазыйфаи затка тоташтырыла (күчерелә) яисә мөрәҗәгать итүчегә кирәкле мәгълүматны алырга мөмкин булган телефон номеры хәбәр ителергә тиеш.

Телефон буенча сөйләшү 10 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел.

5. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча телефоннан шалтыратуларга һәм телдән мөрәҗәгатьләргә җавап биргәндә вазыйфаи зат, кергән мөрәҗәгать нигезендә, түбәндәге мәгълүматны бирергә тиеш:

дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләрен җайга салучы норматив хокукый актлар турында (норматив хокукый актның исеме, кабул итү датасы һәм номеры);

дәүләт хезмәтеннән файдалану хокукына ия гражданнар категорияләре исемлеге турында;

дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документлар исемлеге турында;

дәүләт хезмәте күрсәтү чорлары турында;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре турында;

вәкаләтле органының сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүматны урнаштыру урыны турында.

6. Вәкаләтле орган сайтында, «Дәүләт хезмәтләре (функцияләре) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – федераль реестр), Бердәм порталда, шулай ук дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү урыннарындагы стендларда, һәм күпфункцияле үзәктә түбәндәге белешмә мәгълүмат урнаштырыла:

вәкаләтле органның, шулай ук күпфункцияле үзәкләрнең урнашу урыны һәм эш графигы турында;

вәкаләтле органның белешмә телефоннары, шул исәптән автоинформатор-телефон номеры (булган очракта);

рәсми сайт адресы, шулай ук сайттагы электрон почта һәм (яки) кире элемтә формалары.

Вәкаләтле органның кабул итү графигы, гражданнарның мәнфәгатьләрен, төбәкнең климат шартларын исәпкә алып, боерык белән билгеләнә.

Кабул итү чиратлар барлыкка килүне булдырмас өчен, атнага өч көннән дә ешрак булмаган күләмдә оештырылырга тиеш.

7. Бердәм порталда түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге, аталган документларны рәсмиләштерүгә карата таләпләр, шулай ук мөрәҗәгать итүче үз инициативасы нигезендә тапшырырга хокуклы булган документлар исемлеге;

дәүләт хезмәтеннән файдалану хокукына ия гражданнар категорияләре исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны тапшыру тәртибе;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы күләме;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге;

мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү барышында гамәлгә ашырыла торган гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм кабул ителгән карарларга судка кадәр

(судтан тыш) шикаять белдерү хокукы турында;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кулланыла торган гаризаларның (белдерүләрнең, хәбәрләрнең) формалары.

Бердәм порталда федераль реестрдагы мәгълүматлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм чорлары турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында мәгълүматтан файдалану мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы лицензия яки түләү алуны, мөрәҗәгать итүчене теркәүне яки авторлаштыруны яки аның тарафыннан персональ белешмәләр тапшыруны таләп итә торган программа тәэминаты хуҗасы белән башка төрле килешүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гына башкарыла.

Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибендә Бердәм порталда басылып чыккан мәгълүматка туры китереп тапшырылган булса, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

8. Мөрәҗәгать итүчеләргә дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат бирү максатларында, электрон почта аша текстлы хәбәрләр форматында яки кыска текстлы хәбәрләр (мөрәҗәгать итүченең (вәкилнең) күчмә радиотелефон элемтәсен урнаштыруның абонент номеры турындагы белешмәләре булган очракта, мөрәҗәгать итүченең (вәкилнең) күрсәтелгән ысул белән хәбәр итүгә язма ризалыгы булган очракта, Бердәм портал сервисларыннан файдаланып) җибәрелергә мөмкин.

Гаризаны Бердәм портал ярдәмендә электрон документ формасында биргән очракта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан мәгълүмат бирү ысулы, шул исәптән электрон почта адресы, кыска текстлы хәбәрләрне тапшыру өчен күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмасының абонент номеры күрсәтелә.

## II. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

### Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

9. Бала туу һәм тәрбияләү белән бәйле айлык пособие бирү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – айлык пособие).

### Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды тарафыннан үз территориаль органнары аша мөрәҗәгать итүченең яшәү (тору) урыны буенча яисә, расланган яшәү (тору) урыны булмаган очракта – мөрәҗәгать итүченең фактта яшәү урыны буенча гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтле органның территориаль органнары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, шул исәптән башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм оешмаларга

мөрәҗәгать итү белән бәйле гамәлләрне, килештерүләрне гамәлгә ашыруны таләп итәргә хокуклы түгел.

## Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

11. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

айлык пособие билгеләү турында гариза биргәндә айлык пособие билгеләү турында карар чыгару һәм айлык пособие түләү, яки айлык пособие билгеләүдән баш тарту турында карар чыгару;

айлык пособиене китерү ысулын үзгәртү турында гариза биргәндә – тапшыру ысулын үзгәртү турында тапшырылган гариза нигезендә түләү эшенә мәгълүмат кертү.

## Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

12. Айлык пособие билгеләү турында гаризаны карау һәм айлык пособие билгеләү турында яки айлык пособие билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү айлык пособие билгеләү турында гариза теркәлгән көннән алып 10 эш көне эчендә башкарыла.

Айлык пособиене билгеләү яисә айлык пособиене билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү чоры, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында соратып алына торган документлар (белешмәләр) килмәсә яки тиешле вакыттан биш эш көненнән соңрак тапшырылган документлар (белешмәләр) җитәрлек күләмдә булмаса, айлык түләү билгеләү турында гаризаны теркәгән көннән соң 20 эш көненә озайтыла.

Айлык пособиене билгеләүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, вәкаләтле орган бу хакта мөрәҗәгать итүчегә (вәкилгә) мондый карар кабул ителгән көннән соң бер эш көненнән дә артмаган чорда, дәлилләнгән нигезләүне һәм чыгарылган карарга шикаять бирү тәртибен күрсәтеп, хәбәр итә.

13. Акча китерү ысулын үзгәртү турындагы гариза нигезендә түләү эшенә мәгълүмат кертү түләүне китерү ысулын үзгәртү турындагы гаризаны теркәгәннән соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

14. Айлык пособиене билгеләү турында гариза Бердәм порталдан файдаланып бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүче (вәкил) айлык пособиене билгеләү турында гариза теркәгәннән соң 10 эш көне эчендә мөрәҗәгать итүче тапшырырга тиешле документларны (белешмәләрне) вәкаләтле органга тапшыра.

Мөрәҗәгать итүче (вәкил) шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта аның тарафыннан мөрәҗәгать итүче тапшырырга тиешле документлар (белешмәләр) комплекты тулысынча тапшырылмаган очракта, мөрәҗәгать итүче (вәкил) тиешле документларны (белешмәләрне) айлык пособие билгеләү турында гаризаны теркәгәннән соң 10 эш көне эчендә тапшырырга хокуклы.

15. Айлык пособие билгеләү яисә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү чоры мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган гаризада һәм (яки) документларда (белешмәләрдә) төгәл булмаган һәм (яки) тулы булмаган мәгълүмат булуы ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан айлык пособиене

билгеләү турында эшләп бетерелгән гариза һәм (яки) эшләп бетерелгән документлар (белешмәләр) тапшырылган вакытка кадәр туктатып торыла, ләкин биш эш көненнән артмаган чорга кадәр генә.

Айлык пособие билгеләү турында яки билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү чоры айлык пособиене билгеләү турында эшләп бетерелгән гариза һәм (яки) эшләп бетерелгән документлар (белешмәләр) вәкаләтле органга алынган көннән башлап яңадан торгызыла.

16. Айлык пособие, айлык пособие билгеләнгән көннән соң биш эш көненнән соңга калмыйча, айлык акчалата түләүне гамәлгә ашыручы вәкаләтле орган тарафыннан кредит оешмасы яки федераль почта элемтәсе оешмасы аша башкарыла. Аннан соңгы түләүләр айлык акчалата түләүне гамәлгә ашыручы вәкаләтле орган тарафыннан айлык пособие түләнә торган айдан соң килүче айның 1 нче көненнән башлап 25 нче көненә кадәр түләнә.

## Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

17. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (аларның реквизитларын һәм рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп) вәкаләтле орган сайтында, федераль реестрда һәм Бердәм порталда урнаштырыла.

## Норматив хокукый актлар дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле

18. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче (вәкил) тарафыннан түбәндәге документлар тапшырыла:

гариза;

паспорт яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә шәхесне таныклаучы башка документ;

мөрәҗәгать итүче (вәкил) тарафыннан тапшырылырга тиешле, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, әлеге Административ регламентның 20 пунктында каралган документлар.

Мөрәҗәгать итүченең мәнфәгатьләрен ышаныч кәгазе нигезендә яклаган очракта, өстәмә рәвештә вәкилнең шәхесен таныклаучы ышаныч кәгазе һәм документ кирәк. Ышаныч кәгазе нотариаль яктан расланган очракта, мәнфәгатьләре яктыртыла торган мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документны күрсәтү таләп ителми.

19. Айлык пособие билгеләү турында гариза һәм илтеп җиткерү ысулын үзгәртү турында гариза рәвешләре Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бала туугa һәм тәрбияләүгә бәйле рәвештә айлык пособиене билгеләү һәм түләү тәртибе турында» 2022 елның 16 декабрендәге 2330 номерлы карары белән расланган (алга таба – 2330 номерлы карар).

20. Билгеләнү шартларына, шулай ук мөрәҗәгать итүчедә барлыкка килгән

тормыш шартларына бәйле рәвештә, айлык пособие билгеләү турындагы гаризага түбәндәге документлар (белешмәләр) тапшырыла:

туу турында – чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан тиешле акт язуы теркәлгән очракта (Россия Федерациясе законнары нигезендә рус теленә расланган тәрҗемә белән мөрәҗәгать итүче тарафыннан тәкъдим ителә);

баланың үлеме турында – чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан тиешле акт язуы теркәлгән очракта (Россия Федерациясе законнары нигезендә рус теленә расланган тәрҗемәсе булган мөрәҗәгать итүче тарафыннан тәкъдим ителә);

гаилә әгъзасының үлеме турында – чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан тиешле акт язуы теркәлгән очракта (Россия Федерациясе законнары нигезендә рус теленә расланган тәрҗемә белән мөрәҗәгать итүче тарафыннан тәкъдим ителә);

өйләнешү (аерылышу) турында – чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан тиешле акт язуы теркәлгән очракта (Россия Федерациясе законнары нигезендә рус теленә расланган тәрҗемәсе булган мөрәҗәгать итүче тарафыннан тәкъдим ителә);

баланың ата-анасы турында – баланың тууы турында чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан тиешле акт язуы теркәлгән очракта (Россия Федерациясе законнары нигезендә рус теленә расланган тәрҗемәсе булган мөрәҗәгать итүче тарафыннан тәкъдим ителә);

гариза бирелгән баланың (балаларның) опекуны (попечителе) турында – опека (попечительлек) чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан билгеләнгән очракта (Россия Федерациясе законнары нигезендә рус теленә расланган тәрҗемәсе булган мөрәҗәгать итүче тарафыннан тәкъдим ителә);

Россия Федерациясе Җинаять үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәте органнары, Россия Федерациясе дәүләт саклау органнары, Россия Федерациясе Эчке эшләр органнары һәм Россия Федерациясе законнарында хокук саклау эшчәнлеге белән бәйле федераль дәүләт хезмәтен узу каралган башка органнар хезмәткәрләренең керемнәре турында (Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнары, Россия Федерациясе таможня органнары, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсе хезмәткәрләреннән тыш);

хәрби хезмәт, Россия Федерациясе җинаять үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнарында, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәте органнарында, Россия Федерациясе дәүләт сагы органнарында, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарында, Россия Федерациясе таможня органнарында, Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләрендә, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнарында, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсендә хезмәт уза торган (узган) затлар тарафыннан алына торган пенсия күләме турында;

юридик зат төземичә төзелгәнен дә исәпкә алып, крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәрне дә кертеп, эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырудан алынган керемнәр турында;

шәхси практиканы гамәлгә ашырудан алынган керемнәр турында;

авторлык заказы, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә аерым хокукны

читләштерү турындагы килешүләр буенча алынган керемнәр турында;

алына торган алиментлар турында (акчалар түләттерүчегә суд приставлары бүлегенә алиментлар түләттерүгә бәйле эш буенча вакытлыча идарәлеккә күчә торган акчаларны исәпкә алу счетыннан күчерелгән очрактан тыш);

мөрәҗәгать итүче һәм (яки) аның гражданнар белән бер фатирда бергәләп яшәве мөмкин булмаган, катлаулы хроник авыру төрләренең Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган исемлегендә каралган хроник чирнең авыр формасыннан интегүче гаиә әгъзасы яши торган, «торак» билгеләнешендәге бүлмә (аның бер өлеше) турында;

билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган, «торак» билгеләнешендәге бүлмә (аның бер өлеше) турында;

мөрәҗәгать итүчегә яисә аның гаилә әгъзаларына теркәлгән, Россия Федерациясе субъектының вәкаләтле органы яки муниципаль берәмлек тарафыннан дәүләт социаль ярдәме кысаларында бирелгән яисә сатып алу бәясе тулы күләмендә күчемле милек сатып алуга максатчан дәүләт социаль ярдәме кысаларында бирелгән акчалар хисабыннан түләнгән автотранспорт яки мототранспорт чарасы турында;

мөрәҗәгать итүченең яисә аның гаилә әгъзаларының гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында яки югары белем бирү оешмасында көндезге уку формасы буенча белем алуы һәм гаиләнең җан башына уртача кереме исәпләнгән чорда стипендия алу (алмау) факты турында;

мөрәҗәгать итүче яки аның гаилә әгъзаларының 3 айдан артык өзлексез дәвалану үтү факты турында, шуның нәтиҗәсендә гаиләнең җан башына уртача кереме исәпләнгән чорда хезмәт эшчәнлеген вакытлыча башкару мөмкинлегенең булмавы турында;

мөрәҗәгать итүче яки аның гаилә әгъзаларының гаиләнең җан башына уртача кереме исәпләнә торган чорда чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтүе турында;

мөрәҗәгать итүченең һәм (яисә) аның гаилә әгъзаларының тулы дәүләт тәэминатында булуы турында;

мөрәҗәгать итүче яисә аның гаилә әгъзаларының чакырылу буенча хәрби хезмәт үтүе турында, шулай ук хәрби һөнәри оешмада һәм югары белем бирүче хәрби мәгариф оешмасында белем алучы һәм хәрби хезмәт үтү турында контракт төземәгән затның хәрби хезмәткәр статусы турында;

мөрәҗәгать итүченең яисә аның гаилә әгъзаларының суд карары буенча мәҗбүри дәвалауда булуы турында;

һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында укучыларга, фән-педагогика кадрларын әзерләү программалары буенча көндезге рәвештә белем алучы затларга һәм дини белем бирү оешмаларында укучы фән-педагогика кадрларына түләнә торган стипендияләр, Россия Федерациясе законнарында каралган башка акчалата түләүләр, шулай ук медицина күрсәткечләре буенча аларның академия отспускысында булуы чорына гражданнарның күрсәтелгән категорияләренә компенсация күләме хакында;

отставкага киткән судьяларга гомер буе ай саен түләнә тәэминат күләме турында;

дәүләти яисә иҗтимагый бурычларны үтәү вакытына дәүләт органы яисә

иҗтимагый берләшмә тарафыннан түләнә торган, алынган компенсация суммасы турында;

Россия Федерациясеннән читтәге чыганаклардан алынган керем суммалары турында (Россия Федерациясе законнары нигезендә рус теленә расланган тәрҗемәсе булган мөрәҗәгать итүче тарафыннан тәкъдим ителә);

Россия Федерациясе субъектының вәкаләтле органы яки муниципаль берәмлек тарафыннан күпбалалы гаиләгә дәүләт социаль ярдәме кысаларында бирелгән яисә сатып алу бәясе тулы күләмендә күчемсез мөлкәт сатып алуга максатчан дәүләт социаль ярдәме кысаларында бирелгән акчалар хисабыннан түләнгән «торак» билгеләнешендәге бүлмәләр, «торак», «торак төзелеш» һәм «торак йорт» билгеләнешендәге биналар, җир кишәрлекләре турында, шулай ук «Дәүләт яки муниципаль милектә булган һәм Россия Федерациясенең Арктика зонасында һәм Россия Федерациясенең башка, Төньяк, Себер һәм Ерак Көнчыгыш территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен гражданнарга бирү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 1 маендагы 119-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә бирелгән җир кишәрлекләре турында;

хәрби хезмәттән, Россия Федерациясенең җинаять үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнарында, федераль куркынычсызлык хезмәте органнарында, дәүләт сагы органнарында, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарында, Россия Федерациясе таможня органнарында, Россия Федерациясе илкүләм гвардия гаскәрләрендә, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнарында, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсендәге хезмәттән, шулай ук Россия Федерациясе законнарында хокук куллану эшчәнлеге белән бәйле дәүләт хезмәтен узу күздә тотылган башка органнардагы хезмәттән киткәндә бер тапкыр бирелә торган пособие күләме турында;

автотранспорт, мототранспорт чарасы, кече үлчәмле судно, үзйөрешле машина яки башка төр техниканың арестта һәм (яки) эзләтүдә булуы турында, шулай ук аларга карата теркәү гамәлләре тыелган булса;

алынган грантлар, субсидияләр һәм эшкуарлыкка ярдәм итү кысаларында бирелә торган максатчан чыгымнарга ия булган башка керемнәр турында;

йөклелек белән бәйле рәвештә медицина оешмасында исәпкә кую, шулай ук бала тудыру яисә йөклелекне өзү турында (бала тудыру сертификаты булмаган очракта);

21. Илтеп җиткерү ысулын үзгәртү турындагы гаризага өстәмә документлар таләп ителми.

22. Вәкаләтле орган карамагында әлеге Административ регламентның 20 пунктында күрсәтелгән һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле белешмәләр булган очракта, мөрәҗәгать итүче (вәкил) тарафыннан мондый белешмәләрне раслый торган документларны тапшыру таләп ителми.

23. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт яки муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы башка органнар карамагында булган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар вәкаләтле орган тарафыннан алар белән эш итүче органнар һәм (яки) оешмаларда ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында

соратып алына.

Мөрәҗәгать итүче (вәкил) дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы башка органнар карамагында булган, мөрәҗәгать итүче (вәкил) тарафыннан тапшырылырга тиешле дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларга өстәмә рәвештә документларны (белешмәләрне) тапшырырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче (вәкил) тарафыннан әлеге Административ регламентның 24 пунктында күрсәтелгән документларны (мәгълүматларны) тапшырмау дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

24. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт яки муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы башка органнар карамагында булган һәм айлык пособиене билгеләү яки яңартып җибәрү өчен кирәкле документлар (белешмәләр) сыйфатында мөрәҗәгать итүче (вәкил) түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырырга хокуклы:

туу турында;

баланың үлеме турында;

гаилә әгъзасының үлеме турында;

өйләнешү (аерылышу) турында;

баланы опекага алу турында опека һәм попечительлек органы карарындагы мәгълүматлар;

баланың ата-аналары турында;

үзләренә карата гариза бирелгән баланың (балаларның) опекуны (попечителе) турында;

ата-аналык хокукыннан мәхрүм итү (чикләү, торгызу) турында, ата-ана хокукларындагы чикләүләрне гамәлдән чыгару турында, гомеренә яки сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда баланы йолып алу турында;

ата-ананың яки баланың башка законлы вәкиленең хокукка сәләте чикләнгән булуы яисә хокукка сәләтсез дип танылуы турында;

хезмәт яисә башка бурычларны, кызыксындыру характерындагы түләүләрне дә кертеп, бүләкләү, башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт өчен бүләкләү, граждан-хокукый шартнамә кысаларында, шул исәптән түләүле шартларда опека һәм попечительлек гамәлгә ашыру турында шартнамә (тәрбиягә бала алган гаилә турында шартнамә, патронат гаилә турында шартнамә) (шул исәптән салым тотып калынган) буенча гамәл кылган өчен алынган түләү турында;

хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе Илкүләм гвардиясе гаскәрләре, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәү органнары, Россия Федерациясе таможня органнары, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсе хезмәткәрләре керемнәре турында;

пенсия, пособиеләр һәм башка шундый ук түләүләр, шул исәптән мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча һәм Россия Федерациясе законнары һәм (яисә) Россия Федерациясе субъекты законнары нигезендә алынган компенсация характерындагы түләүләрнең суммалары турында;

Россия Федерациясенең мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе турында законнарында каралган очракларда вафат булган иминиятләштерелгән затларның хокукый варисларына түләүләр турында;

җан башына исәпләгәндә уртача керемен исәпләү чорында эшкә сәләтсез затларны карау турында;

гариза бирү вакытына һәм (яки) гаиләнең җан башына исәпләгәндә кереме исәпләнгән чорда эшсез яки эш эзләүче статусы булуы турында;

кыйммәтле кәгазьләр белән операцияләр һәм җитештерү финанс инструментлары белән операцияләр (тотылган чыгымнарны исәпкә алып) буенча алынган дивидендлар, процентлар һәм башка керемнәр турында, шулай ук оешма милке белән идарә итүдә катнашуга бәйле рәвештә дә;

кредит учреждениеләрендә кертемнәр буенча алынган процентлар турында;

эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүләрдән алынган керемнәр, крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат төземичә хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәр һәм шәхси практика башкарудан алынган керемнәр турында;

авторлык заказы, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә аерым хокукны читләштерү турындагы килешүләр буенча алынган керемнәр турында;

Россия Федерациясе Салым кодексының 217[1] статьясында күрсәтелгән сроктан азрак вакыт эчендә милектә булган күчемсез милекне сатудан, шулай ук мөлкәтне арендага (наемга, поднаемга) бирүдән алынган керемнәр турында;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрындагы күчемсез мөлкәт турында (шул исәптән арест астында булган);

Россия Федерациясе гражданинының Россия Федерациясе чикләрендә яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлүе турында;

Россия Федерациясе территориясендә Россия Федерациясе гражданинының шәхесен таныклый торган, Россия Федерациясе гражданинына элек бирелгән паспортлар турында;

алына торган алиментлар турында (әгәр акчалар түләттерүчегә суд приставлары бүлегенә алиментлар түләттерүгә бәйле эш буенча вакытлыча идарәлеккә күчә торган акчаларны исәпкә алу счетыннан күчерелгән булса);

автотранспорт яки мототранспорт чаралары турында;

чыгару елы 5 елдан артмаган кече үлчәмле су суднолары турында;

гаиләнең җан башына исәпләгәндә уртача кереме исәпләнә торган чорга мөрәҗәгать итүчене яки аның гаилә әгъзаларын иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат итү турында;

мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзаларының иректән мәхрүм ителү урыннарында булуы турында;

инвалидлык һәм аның төркеме турында (булган очракта);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканы дәүләт теркәвенә алу кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 21 сентябрендәге 1507 номерлы карары белән расланган Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканы дәүләт теркәвенә алу кагыйдәләре нигезендә теркәлгән үзйөрешле машиналар һәм башка төр техника турында;

мөрәҗәгать итүчегә яки аның гаилә әгъзаларына карата сак астына алу рәвешендә чикләү чарасын куллану турында;

табигый бәла-казага яки башка гадәттән тыш хәлләргә бәйле рәвештә, шулай ук террорлык акты белән бәйле рәвештә федераль бюджет, Россия Федерациясе

субъектлары бюджетлары, җирле бюджетлар һәм башка чыганаклар акчалары исәбеннән түләнә торган бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм суммалары турында;

йөклелек белән бәйле рәвештә медицина оешмасында исәпкә кую, шулай ук бала тудыру яисә йөклелекне өзү турында;

«күпбалалы» гаилә статусы турында;

лотереяны оештыручылар, тотализаторлар тарафыннан һәм хәтәрлеккә нигезләнгән башка уеннардан түләнә торган, отыш нәтиҗәсендә алынган керемнәр турында;

мөрәҗәгать итүчене һәм (яисә) аның гаилә әгъзаларын Россия Федерациясе законнары нигезендә Россия Федерациясенең төп аз санлы халыкларына кертү һәм традицион яшәү рәвешен алып баруы турында;

хезмәт эшчәнлеге турында;

«Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллану кысаларында алынган керемнәр турында.

25. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә вәкаләтле орган мөрәҗәгать итүчедән (вәкилдән) түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

мөрәҗәгать итүче (вәкил) тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткәнгә түләү кертелүен раслый торганын да исәпкә алып, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон) 7 статьясының 6 өлешендә күрсәтелгәннәрдән тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актлары һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә органнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары карамагында яки дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагында булган документларны һәм мәгълүматлар тапшыруны;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны;

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә электрон рәвешләре элегрәк таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту**

**нигезләренең тулы исемлеге**

26. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән затның шәхесен билгеләмәү (әлеге зат тарафыннан аның шәхесен таныклый торган документның күрсәтелмәве, әлеге затның үз шәхесен таныклый торган документны күрсәтүдән баш тартуы, гамәлдә булу чоры узган шәхесне таныклый торган документның күрсәтелүе);

мөрәҗәгать итүче вәкиле вәкаләтләрен расламау;

мөрәҗәгать итүче аңа карата дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән баланың законлы вәкиле вәкаләтләрен расламау;

гаризаны Бердәм портал ярдәмендә электрон рәвештә тапшырган очракта, гражданинның электрон гаризасының чын булуын тикшерү нәтиҗәсендә аның «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә чын булуын тану шартларының үтәлмәве.

Башка очракларда документларны кабул итүдән баш тарту рөхсәт ителми.

**Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге**

27. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

айлык пособие билгеләү турында гариза бирелгән баланың үлемен дәүләт теркәвенә алу;

гаиләнең җан башына исәпләгәндә уртача кеременең халыкның җан башына исәпләгәндә яшәү минимумы күләмен арттырып җибәрүе;

2330 номерлы карар белән расланган «Балалы гражданнарга дәүләт пособиеләре турында» федераль законда билгеләнмәгән өлештә бала туу һәм тәрбияләү белән бәйле рәвештә айлык пособие билгеләү һәм түләү кагыйдәләренең (алга таба – Кагыйдәләр) 35 пунктында каралган очрактан тыш, айлык пособие билгеләү турында гаризада дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар булуы;

аңа карата айлык пособие билгеләү турында гариза алынган баланың 17 яшен тутыруы;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан документларны (белешмәләрне) тапшырмау, шулай ук документларны (белешмәләрне) Кагыйдәләрнең 26 һәм 27 пунктларында күрсәтелгән срокларда тапшырмау (2330 номерлы карар белән расланган Бала тууга һәм тәрбияләүгә бәйле рәвештә айлык пособие билгеләү өчен кирәкле документлар (документлар, белешмәләр) исемлегенең 22 һәм 24 пунктларында каралган очраклардан тыш);

айлык пособие билгеләү турындагы гаризаны һәм (яки) документларны Кагыйдәләрнең 35 пункты нигезендә эшләп бетерү өчен кире кайтарганнан соң 5 эш көне эчендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан айлык пособиене билгеләү турында кирәкле гаризаның һәм (яки) документларның (белешмәләрнең) тапшырылмавы:

17 яшькә кадәрге Балалы гражданнарга айлык пособие билгеләү турында гариза бирелгән бала буенча айлык пособиенең аның башка законлы вәкиленә билгеләнү фактын ачыклау;

мөрәҗәгать итүченең һәм (яисә) аның гаилә әгъзаларының түбәндәге күчемсез мөлкәт объектлары, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының гомуми өлеш милкендәге мөлкәтләре булу (опекадагы (попечительлектәге) балалар милегендәге күчемсез мөлкәт объектларыннан (аларның өлешләреннән), җыеп исәпләгәндә барлык гаилә әгъзаларына күчемсез мөлкәткә карата гомуми өлешле милекчелек өлеше аның гомуми мәйданының өстән береннән артмаган өлешләрдән, арестта булган һәм (яки) аларга карата теркәү гамәлләре тыелган күчемсез мөлкәт объектларыннан (аларның өлешләреннән) тыш):

суммар мәйданы бер кешегә һәм гаилә әгъзалары санына исәпләгәндә 24 кв. метрга тапкырчыгыштан зуррак булган 2 һәм аннан күбрәк «торак» билгеләнешендәге бина (Россия Федерациясе субъектының яки муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы тарафыннан, күпбалалыны да кертеп, гаиләгә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү кысаларында бирелгән яисә сатып алу бәясе тулы күләмендә күчемсез мөлкәт сатып алуга максатчан дәүләт социаль ярдәмен бирү кысаларында бирелгән акча хисабыннан түләнгән шундый торак урыннан тыш) (ана (гаилә) капиталы акчаларыннан тыш), Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы раслаган бер фатирда гражданнарның бергә яшәве мөмкин булмаган хроник чирләрнең катлаулы формалары исемлегендә каралган хроник чирнең катлаулы формасыннан интегә торган мөрәҗәгать итүче һәм (яки) аның гаилә әгъзасы биләп торган торак урын (аның бер өлеше), шулай ук билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урыннан (аның бер өлешеннән) тыш);

«торак», «торак төзелеш» һәм «торак йорт» билгеләнешендә, суммар мәйданы бер кешегә һәм гаилә әгъзалары санына исәпләгәндә 40 кв.метр тапкырчыгышыннан күбрәк булган 2 һәм аннан күбрәк бина (Россия Федерациясе субъектының яки муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы тарафыннан, күпбалалыны да кертеп, гаиләгә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү кысаларында бирелгән яисә сатып алу бәясе тулы күләмендә күчемсез мөлкәт сатып алуга максатчан дәүләт социаль ярдәмен бирү кысаларында бирелгән акча хисабыннан түләнгән шундый торак урыннан тыш) (ана (гаилә) капиталы акчаларыннан тыш));

«бакча йорты» билгеләнеше белән 2 һәм аннан күбрәк бина;

«торак булмаган» билгеләнеше булган 2 һәм аннан күбрәк бина, «торак булмаган» билгеләнешле бүлмәләр, корылмалар (индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләрендә, бакча җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмаларыннан һәм тәэмин итү функцияләре булган корылмалардан тыш, шулай ук күпфатирлы йортта гомуми милек булып торган күчемсез мөлкәт объектларыннан, бакчачылык яки яшелчәчелек коммерциясез ширкәтенең гомуми файдалану милеге булып торган күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш);

транспорт чараларын кую (саклау), ремонтлау һәм техник хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән 2 һәм аннан күбрәк күчемсез мөлкәт (гараж, машина урыны) (шундый 3 һәм аннан күбрәк күчемсез мөлкәт объекты – күпбалалы гаиләләр, составында

инвалид булган гаиләләр, автотранспорт яки мототранспорт чарасы дәүләт социаль ярдәме кысаларында Россия Федерациясе субъектының вәкаләтле дәүләт хакимияте органы яки муниципаль берәмлек тарафыннан бирелгән яки автотранспорт яки мототранспорт чарасын сатып алу бәясе тулы күләмендә максатчан дәүләт социаль ярдәме кысаларында күчемле мөлкәт сатып алу өчен бирелгән акчалар хисабыннан түләнгән гаиләләр өчен) (региональ ана (гаилә) сертификаты акчаларыннан тыш);

җир кишәрлеге (җир кишәрлекләре) (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге, әйләнеше «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» федераль закон нигезендә җайга салына торган җирләрдән, Россия Федерациясе субъектының вәкаләтле органы яки муниципаль орган тарафыннан күпбалалы гаиләләргә дәүләт социаль ярдәме кысаларында бирелгән яки сатып алу бәясе тулы күләмендә күчемсез мөлкәт сатып алуга максатчан дәүләт социаль ярдәме кысаларында бирелгән акчалар хисабыннан түләнгән җир кишәрлекләреннән тыш һәм «Дәүләт һәм муниципаль милектә булган һәм Россия Федерациясенең Арктика зонасында һәм Россия Федерациясенең башка, Төньяк, Себер һәм Ерак Көнчыгыш территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен гражданнарга бирү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон нигезендә бирелгән җир кишәрлекләреннән тыш), аларның суммар мәйданы мөрәҗәгать итүченең яшәү (тору) урыны яки, яшәү (тору) урыны расланмаган очракта, хакыйкый яшәү урыны буенча билгеләнә һәм 0,25 гектардан артмаска тиеш, ә шәһәр округлары составында муниципаль берәмлекләр булып тормаган авыл җирлекләре яки җирлекара территорияләр өчен – 1 гектар;

мөрәҗәгать итүчедә һәм (яки) аның гаилә әгъзаларында теркәлгән (мөрәҗәгать итүчедә һәм аның гаилә әгъзаларында теркәлгән автотранспорт (мототранспорт) чараларын билгеләгән очракта) чаралар, кече үлчәмле суднолар, үзйөрешле машиналар яки башка төр техника булуы, арестта һәм (яки) эзләтүдә булган, үзләренә карата теркәү гамәлләре тыелган, шулай ук опекада (попечениедә) торучы балалар милегендә торган күчемле мөлкәтнең шундый төрләре исәпкә алынмый):

2 һәм аннан күбрәк автотранспорт чарасы (3 һәм аннан күбрәк автотранспорт чарасы – күпбалалы гаиләләр, составында инвалид булган гаиләләр, автотранспорт чарасы дәүләт социаль ярдәме кысаларында Россия Федерациясе субъектының вәкаләтле органы яки муниципаль берәмлек тарафыннан бирелгән яки автотранспорт чарасын сатып алу бәясе тулы күләмендә максатчан дәүләт социаль ярдәме кысаларында күчемле мөлкәт сатып алу өчен бирелгән акчалар хисабыннан түләнгән гаиләләр өчен), тагылмалар һәм ярымтагылмалардан тыш (региональ ана (гаилә) сертификаты акчаларыннан тыш);

2 һәм аннан күбрәк мототранспорт чарасы (3 һәм аннан күбрәк мототранспорт чарасы – күпбалалы гаиләләр, составында инвалид булган гаиләләр, мототранспорт чарасы дәүләт социаль ярдәме кысаларында Россия Федерациясе субъектының вәкаләтле органы яки муниципаль берәмлек тарафыннан бирелгән яки мототранспорт чарасын сатып алу бәясе тулы күләмендә максатчан дәүләт социаль ярдәме кысаларында күчемле мөлкәт сатып алу өчен бирелгән акчалар хисабыннан түләнгән гаиләләр өчен) (региональ ана (гаилә) сертификаты акчаларыннан тыш);

двигателенең куәте 250 ат көченнән ким булмаган, чыгарылган елы 5 елдан артмаган автотранспорт чарасы, 4 һәм аннан күбрәк балалы гаилә алган (сатып алган) автотранспорт чарасыннан тыш;

чыккан елы 5 елдан артмаган 2 һәм аннан да күбрәк кече суднолар;

чыгарылган елы 5 елдан артык булмаган 2 һәм аннан да күбрәк үзйөрешле машина (3 һәм аннан да күбрәк Үзйөрешле машиналар һәм 5 елдан артмаган башка төр техника) үзйөрешле машина һәм техниканың башка төре дәүләт социаль ярдәме кысаларында Россия Федерациясе субъектының вәкаләтле органы яки муниципаль берәмлек тарафыннан бирелгән яки мототранспорт чарасын сатып алу бәясе тулы күләмендә максатчан дәүләт социаль ярдәме кысаларында күчемле мөлкәт сатып алу өчен бирелгән акчалар хисабыннан түләнгән гаиләләр өчен) (региональ ана (гаилә) сертификаты акчаларыннан тыш);

мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының банклардагы кертемнәр (счетлардагы калдыклар) буенча процентлар рәвешендә җан башына исәпләгәндә яшәү минимумы күләменнән артып киткән кереме булуы (керем алынган кертем (счет) айлык пособие билгеләү өчен мөрәҗәгать итү аена кадәр 6 айдан да соңга калмыйча ябылган очрактан тыш);

мөрәҗәгать итүчедә яки аның гаиләсенең эшкә яраклы әгъзаларында (18 яше тулмаган яшьтәге балалардан тыш) Кагыйдәләрнең 48 пунктында каралган хисап чорына Кагыйдәләрнең 47 пунктындагы «е», «к», «м» - «о» и «р» пунктчаларында каралган керемнәрнең (шулай ук аларның чит илләрдә алынган эквивалентларының) булмавы, әлеге чорга туры килә торган түбәндәге (җыеп исәпләгәндә) очраклардан тыш:

мөрәҗәгать итүченең һәм (яки) аның эшли торган гаилә әгъзаларының 6 айдан артыграк эшсезлек статусында булуы;

мөрәҗәгать итүче һәм (яки) аның гаилә әгъзалары баланы 3 яше тулганчы карап торган очракта;

мөрәҗәгать итүче һәм (яки) аның гаиләсе әгъзалары гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында яки югары белем бирү оешмасында көндезге уку формасы буенча (өстәмә белем бирү программалары буенча гына укудан тыш) укыган һәм стипендия алмаган очракта;

мөрәҗәгать итүче һәм (яки) аның гаилә әгъзалары Россия Федерациясе Президентының «Инвалид балаларны һәм балачактан I төркем инвалидларны караучыларга айлык түләүләр турында» 2013 елның 26 февралендәге 175 номерлы Указына ярашлы рәвештә 18 яшькә кадәрге инвалид баланы яки балачактан I төркем инвалидны карау белән шөгыльләнгән очракта;

мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) аның гаилә әгъзалары Россия Федерациясе Президентының «Эшкә сәләтсез гражданнарны караучыларга компенсация түләүләре турында» 2006 елның 26 декабрендәге 1455 номерлы Указына ярашлы рәвештә I төркем инвалидны яки дәвалау учреждениесе нәтиҗәсе буенча даими нигездә башка кешеләр каравына мохтаҗ булган өлкән яисә 80 яшькә җиткән кешене караган очракта;

мөрәҗәгать итүченең һәм (яки) аның гаилә әгъзаларының 3 айдан артык вакыт дәвамында өзлексез дәвалануы, шуның нәтиҗәсендә вакытлыча хезмәт эшчәнлеген башкара алмавы. Бу очрак гаилә составына керә торган бала 3 айдан артык булган

өзлексез вакыт дәвамында дәвалау узган булса, бары тик мөрәҗәгать итүчегә генә яисә аның гаилә әгъзаларының берсенә генә кагыла;

мөрәҗәгать итүченең һәм (яки) аның гаилә әгъзаларының хәрби хезмәт узуы (демобилизация көненә кадәр 3 айдан артмаган чорны да кертеп);

мөрәҗәгать итүченең һәм (яки) аның гаилә әгъзаларының иректән мәхрүм ителүе яки сак астында тотылуы (ireккә чыгу көненә кадәр 3 айдан артмаган чорны да кертеп);

мөрәҗәгать итүченең балигълык яшенә җитмәгән баласының (балаларының) бердәнбер ата-анасы (законлы вәкиле) булып торуы (булуы);

мөрәҗәгать итүченең гаиләсе күп балалы булуы. Бу очрак мөрәҗәгать итүченеңгә яки аның гаилә әгъзаларының берсенә генә кагыла;

мөрәҗәгать итүче-хатын-кыз һәм (яки) мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзалары йөкле булган (Тәртип һәм шартларның 31 пунктында каралган вакытка туры килә торган 6 ай һәм аннан күбрәк вакыт эчендә йөклелек дәвамлылыгы шартында, яисә хатын-кызның йөклелек вакыты – 12 атна һәм аннан күбрәк булса, әлеге пунктчада күрсәтелгән нигез буенча айлык пособие билгеләү турында гариза биргән көндә әлеге нигез буенча айлык пособиене билгеләү турында карар кабул ителми).

мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) аның гаилә әгъзалары Төньяк, Себер һәм Ерак Көнчыгыш халыкларының төп халыкларына карыйлар, традицион яшәү рәвешен һәм территориясендә аз санлы халык яши торган һәм айлык пособие билгеләү турында гариза бирелгән Россия Федерациясе субъектында традицион хуҗалык эшчәнлеген алып баралар;

айлык пособиенең гомуми күләме айлык пособие билгеләү турында гариза бирелгән балага карата җан башына уртача керемне бәяләүне исәпкә алып бирелә торган һәм алына торган социаль ярдәм чараларының гомуми күләменнән кечерәк.

28. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигез булып мөрәҗәгать итүче (вәкиле) тарафыннан бирелгән айлык пособие билгеләү турындагы гаризада һәм (яисә) документларда (белешмәләрдә) дөрес булмаган һәм (яисә) тулы булмаган мәгълүмат булуы фактының ачыклануы тора, шул исәптән мөрәҗәгать итүче айлык пособиене билгеләү турындагы гариза чынлыкта яшәү урыны адресын күрсәтеп, аның Россия Федерациясе территориясендә яшәү (тору) урыны булу факты билгеләнгән очракта да.

## Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

29. Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә.

## Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты

30. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минут тәшкил итә.

**Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры**

31. Мөрәҗәгать итүче (вәкил) дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап турыдан-туры вәкаләтле органга, күпфункцияле үзәк аша яисә гаризаны электрон формада юллау һәм бер мәгънәле һәм конфиденциаль, шулай ук электрон формада арадаш хәбәрләр һәм җавап мәгълүматы алу мөмкинлеген тәэмин итә торган Бердәм портал ярдәмендә, шул исәптән Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә электрон имзаны кулланып та җибәреп мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

32. Турыдан-туры вәкаләтле органга бирелгән гаризаны теркәү мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтле органга күпфункцияле үзәк аша яки Бердәм порталны кулланып, электрон документ формасында җибәрелгән гаризаны теркәү әлеге Административ регламентның 48 пунктында күрсәтелгән чорларда гамәлгә ашырыла.P386

33. Вәкаләтле орган тарафыннан гариза һәм тапшырылган документларны кабул итү факты һәм датасы вәкаләтле орган тарафыннан бирелә торган белдерү белән раслана, анда гаризаны кабул итү датасы, мөрәҗәгать итүче (вәкил) тарафыннан тапшырылган документлар исемлеге, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хезмәтләрен күрсәтүдә катнашучы башка органнар карамагында булган, вәкаләтле орган тарафыннан соратып алына торган һәм мөрәҗәгать итүче (вәкил) үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы булган, җитмәгән документлар исемлеге күрсәтелә.

Белдерү мөрәҗәгать итүченең (вәкилнең) теләге буенча мөрәҗәгать итүченең (вәкилнең) электрон почтасына җибәрелергә мөмкин.

Айлык пособиене билгеләү турындагы гаризага дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле барлык документлар да беркетелмәгән очракта, аларны тапшыру йөкләмәсе мөрәҗәгать итүчегә йөкләнгән булса, мөрәҗәгать итүче (вәкил) вәкаләтле орган аңлатмасы нигезендә җитешмәгән документларны тапшырырга хокуклы.

Вәкаләтле органның тиешле аңлатмасын мөрәҗәгать итүче (вәкил) тарафыннан алу көне дип санала:

мөрәҗәгать итүчегә (вәкилгә) гаризаны кабул иткәндә белдерүне турыдан-туры бирү көне;

мөрәҗәгать итүченең (вәкиленең) электрон почтасына белдерү җибәрү көне;

күпфункцияле үзәктә мөрәҗәгать итүчегә (вәкилгә) белдерү бирү көне. Әгәр мөрәҗәгать итүчегә (вәкилгә) белдерү ул күпфункцияле үзәккә белдерүне алу өчен килмәүгә бәйле рәвештә бирелмәсә, белдерү вәкаләтле орган тарафыннан күпфункцияле үзәккә тапшырылганнан соң биш календарь көн эчендә бирелгән дип санала;

Бердәм порталны кулланып, белдерүне электрон документ рәвешендә җибәрү көне.

Вәкаләтле орган аңлатмасы нигезендә мөрәҗәгать итүче (вәкил) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тиешле документларны тапшырмаган очракта, аларны

тапшыру йөкләмәсе мөрәҗәгать итүчегә йөкләнгән булса, әлеге Административ регламентның 14 пунктындагы икенче абзацында каралган чорда орган әлеге Административ регламентның 12 пунктында каралган чорда дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында карар кабул итә.

34. мөрәҗәгать итүче (вәкиле) тарафыннан бирелгән айлык пособие билгеләү турындагы гаризада һәм (яисә) документларда (белешмәләрдә) дөрес булмаган һәм (яисә) тулы булмаган мәгълүмат булуы факты, шул исәптән мөрәҗәгать итүче айлык пособиене билгеләү турындагы гариза чынлыкта яшәү урыны адресын күрсәтеп, аның Россия Федерациясе территориясендә яшәү (тору) урынының булу факты билгеләнгән очракта, вәкаләтле орган айлык пособие билгеләү турындагы мондый гаризаны һәм (яки) документларны (белешмәләрне), төзәтелергә тиешле мәгълүматны күрсәтеп, эшләп бетерү өчен мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарып бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче (вәкил) эшләп бетерелгән гаризаны һәм (яки) документларны (белешмәләрне) аларны кире кайтарганнан соң 5 эш көне эчендә тапшыра.

35. Гаризаны кабул итү, теркәү һәм тапшырылган документларны бәяләү 30 минуттан артмаска тиеш.

**Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр**

36. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләрнең (алга таба – бүлмәләр) урнашу урыны җәмәгать транспорты тукталышларыннан җәяүлеләр өчен уңайлы булырга тиеш.

Җәмәгать транспорты тукталышларыннан бүлмә урнашкан бинага (корылмага) кадәр юл тиешле мәгълүмати күрсәткечләр белән җиһазландырылырга тиеш.

Бүлмә урнашкан бина (корылма) янындаг тукталу (машина кую) урыны оештырылган очракта, гражданнарның шәхси автомобиль транспорты өчен тукталу (машина кую) урыны оештырыла. Тукталу (машина кую) урыныннан файдаланган өчен түләү алынмый.

Халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәренең махсус автотранспорт чараларын кую өчен машиналарны туктата торган һәр урыннарның кимендә 10%ы (кимендә бер урын) бүлеп бирелә, аларны башка төрле транспорт чаралары алырга тиеш түгел.

Бүлмәләр биналарның аскы, өстенлекле рәвештә беренче катларында аерым керү юлы белән урнашкан булырга тиеш.

37. Бүлмәгә керү гражданнар өчен ирекле файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итәргә, шулай ук кресло-коляскалар белән хәрәкәт итү өчен тоткычлары булган уңайлы баскычлар, киң керү уемнары, махсус коймалар һәм култыксалар, пандуслар белән җиһазландырылган булырга тиеш. Бүлмә буйлап хәрәкәт итү сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгән затларга кыенлыклар тудырырга тиеш түгел, кресло-коляскалардан файдаланучыларны да исәпкә алып.

Бүлмә урнашкан бинага (корылмага) үзәк керү урыны түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат табличкасы (элмә такта) белән җиһазландырыла:

вәкаләтле органның исеме;

эш режимы;

кабул итү графигы.

38. Бүлмәләр чират белән идарә итүнең электрон системасы, утлы мәгълүмат таблосы, һаваны кондиционирлау системасы, янгын системасы һәм янгын сүндерү чаралары, сак һәм видеокүзәтү системасы белән җиһазландырыла.

Бүлмә урнашкан бинаның (корылманың) фасады гражданнарга мәгълүмат табличкасы белән танышырга мөмкинлек бирүче яктырту приборлары белән җиһазландырылырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүчеләргә аларның, үзләренә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатын исәпкә алып, вәкаләтле органдагы җитәкчеләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләүдә катнашу мөмкинлеге турында мәгълүмат җиткерү максатларында бүлмәдә (көтү урынында) мөрәҗәгать итүчеләрнең дәүләт хезмәтләре күрсәтелүнең сыйфатын бәяләүдә катнашу мөмкинлеге турында белешмәләрне үз эченә алган мәгълүмат материаллары урнаштырыла.

Бүлмәләр көтү залын һәм гражданнарны кабул итү урыннарын үз эченә ала. Көтү залы документларны рәсмиләштерү өчен урындыклар, өстәлләр (стойкалар) белән җиһазландырыла. Көтү урыннары саны аларның чын йөкләнешенә һәм аларны бинада урнаштыру мөмкинлекләренә карап билгеләнә. Көтү залында белешмә-хокукый системалары һәм программа продуктлары булган компьютер урнаштырылырга тиеш. Аның белән эшләү кагыйдәләре, шулай ук компьютер эше өчен җаваплы булган вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), телефон номеры, кабинет номеры компьютер янәшәсендә урнашкан мәгълүмат стендында урнаштырыла.

39. Бинага кергәндә һәм (яки) көтү залларында мәгълүмат стендлары урнаштырыла. Мәгълүмат стендларында түбәндәге мәгълүмат һәм документлар урнаштырыла:

вәкаләтле органның почта адресы;

сайтның адресы;

вәкаләтле органның белешмә телефоны номеры, телефон-автоинформатор номеры (булган очракта);

вәкаләтле органның эш режимы;

дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшчәнлекне җайга салучы нормаларны үз эченә алган норматив хокукый актлардан өземтәләр;

дәүләт хезмәтеннән файдалану хокукына ия гражданнар категорияләре исемлеге;

дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документлар исемлеге;

гариза формалары һәм аларны тутыру үрнәкләре.

Гражданнарны дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча кабул итү гражданнарны кабул итү өчен махсус җиһазландырылган кабинкаларда (кабинетларда) гамәлгә ашырыла, алар мәгълүмат табличкалары белән тәэмин ителә, түбәндәгеләрне күрсәтеп:

кабинка (кабинет) номерын;

вазыйфаи затның фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта).

Вазыйфаи затның эш урыны белешмәләренең кирәкле мәгълүмат

базаларыннан файдалану мөмкинлеге белән персональ компьютер, принтер һәм сканер белән җиһазландырылырга тиеш.

Физик мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен (шул исәптән кресло-коляскалардан һәм ияртеп йөрүче этләрдән файдаланучы затлар өчен) түбәндәгеләрне тәэмин ителергә тиеш:

каршылыксыз керү шартларын;

объектлар урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итә алу, шулай ук мондый объектларга керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеген, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып та;

күрү функциясе тотрыклы бозылган инвалидларга мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итү, ярдәм күрсәтү мөмкинлеген;

инвалидларның тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, инвалидларның тоткарлыксыз үтеп керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат чыганакларын тиешенчә урнаштыру шартларын;

инвалидлар өчен кирәкле булган, ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү мөмкинлеген;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, озата йөри торган этне кертү мөмкинлеген;

дәүләт хезмәтләре күрсәтүче вәкаләтле органнар хезмәткәрләренең инвалидларга, башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтүгә комачаулаучы киртәләрне җиңеп чыгуда тиешле ярдәм итүен.

Инвалидның ихтыяҗын исәпкә алып, объектны тулысынча җайлаштыру мөмкин булмаган очракта, әлеге объект милекчесе инвалидка дәүләт хезмәте күрсәтү урынына килү мөмкинлеген яисә, мөмкин булган очракта, аны инвалидның яшәү урыны буенча яки читтән торып күрсәтү мөмкинлеген тәэмин итә.

Россия Федерациясе Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Хезмәт, мәшгульлек һәм халыкны социаль яклау өлкәсендә инвалидларның һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемле булуы шартларын тәэмин итү һәм шул ук вакытта аларга кирәкле ярдәмне күрсәтү тәртибен раслау турында» 2015 елның 30 июлендәге 527н номерлы боерыгы белән расланган Хезмәт, мәшгульлек һәм халыкны социаль яклау өлкәсендә инвалидларның һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемле булуы шартларын тәэмин итү һәм шул ук вакытта аларга кирәкле ярдәмне күрсәтү тәртибе.

**Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре**

40. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуын һәм сыйфатын бәяләү түбәндәге күрсәткечләр буенча гамәлгә ашырылырга тиеш:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүчеләрнең (вәкилләрнең) хәбәрдарлык дәрәҗәсе (дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат алу, мәгълүмат алу ысулын сайлау мөмкинлеге);

мөрәҗәгать итүче (вәкил) тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү рәвешләрен, шул исәптән гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләрен (шул исәптән «Интернет» челтәрен) кулланып, Бердәм порталны да кертеп, сайлау мөмкинлеге;

дәүләт хезмәт күрсәтүне сорап күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать итү мөмкинлеге, шул исәптән күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гариза ярдәмендә дә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шул исәптән халыкның хәрәкәт итү мөмкинлеге чикле булган төркемнәре өчен дә, мөрәҗәгать итү мөмкинлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтү срокларының һәм дәүләт хезмәте күрсәткәндә административ процедураларны үтәү срокларының үтәлүе;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләр (вәкилләр) тарафыннан нигезләнгән шикаятьләрнең булмавы;

Бердәм порталны кулланып, электрон документ формасында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар (аларда булган белешмәләр) тапшыру мөмкинлеген бирү;

дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеген бирү.

41. Бердәм порталны кулланып, электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә түбәндәге административ процедуралар гамәлгә ашырыла:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат бирү;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирү өчен кабул итүгә язылу;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалаштыру;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү;

гражданин тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында белешмәләр алу;

дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләү;

дәүләт хезмәте күрсәткәндә вәкаләтле органнарның, аларның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү.

42. Дәүләт хезмәте күрсәтү, консультацияләр һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат бирү максатларында мөрәҗәгать итүчеләрне (вәкилләрне) алдан язылу буенча кабул итү рөхсәт ителә.

Кабул итүгә язылу мөрәҗәгать итүченең шәхси мөрәҗәгате яки телефон элемтәсе чараларын кулланып, шулай ук Интернет челтәре аша да, шул исәптән Бердәм портал аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә кабул итү өчен теләсә нинди ирекле датага һәм вакыт чикләрендә вәкаләтле органда билгеләнгән график буенча гражданнарны кабул итү мөмкинлеге бирелә.

Мөрәҗәгать итүчеләрне (вәкилләрне) алдан язылу буенча кабул итү гражданнарны кабул итүнең билгеләнгән графигы нигезендә эш көне дәвамында башкарыла.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда, мөрәҗәгать итүчегә (вәкилгә) шәхси мөрәҗәгать юлы белән талон-раслама бирелә, ул гаризаны бирү датасы һәм вакыты турында мәгълүматны үз эченә ала.

Телефон аша алдан язылган очракта мөрәҗәгать итүчегә (вәкилгә) документларны кабул итү датасы һәм вакыты хәбәр ителә, ә мөрәҗәгать итүче (вәкил) электрон почта адресын хәбәр иткән очракта, күрсәтелгән адреска шулай ук талон-раслама җибәрелә.

Сайт һәм Бердәм портал аша алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә (вәкилгә) талон-расламаны чыгартып алу мөмкинлеге бирелә.

Мөрәҗәгать итүчеләр (вәкилләр) өчен билгеле бер датага язылу вакыты әлеге дата башланырга бер тәүлек калгач бетә.

Кабул итүгә алдан язылган вакытта билгеләнгән кабул итү вакыты башланып, 15 минут узганнан соң да килмәгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә алдан язылуның гамәлдән чыгарылуы турында мәгълүмат җиткерелә.

Мөрәҗәгать итүче (вәкил) теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

43. Мөрәҗәгать итүченең (вәкилнең) дәүләт хезмәте күрсәткәндә вәкаләтле органның вазыйфаи затлары белән хезмәттәшлеге бер тапкыр – барлык кирәкле документлар белән гариза биргәндә башкарыла.

Гаризаны Бердәм портал аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүченең (вәкилнең) вәкаләтле органның вазыйфаи затлары белән үзара хезмәттәшлеге бер тапкыр – вәкаләтле органга дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны тапшырганда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең (вәкилнең) вәкаләтле органның вазыйфаи заты белән үзара хезмәттәшлек итүенең вакыт озынлыгы 30 минуттан артмый.

44. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый.

45. Гражданин дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап күпфункцияле үзәк аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы (вәкаләтле орган һәм күпфункцияле үзәк арасында үзара ярдәм итешү турында килешү төзелгән очракта һәм әлеге гаризаны тапшыру килешүдә каралган, күпфункцияле үзәктә күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлегендә каралган очракта).

**Дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата, шул исәптән күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү үзенчәлекләрен һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган башка таләпләр**

46. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрне (вәкилләрне) кабул итү вазыйфаи зат тарафыннан вәкаләтле орган оештырган күчмә кабул итү вакытында гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Сәламәтлеге буенча вәкаләтле органга мөрәҗәгать итү мөмкинлеге булмаган

мөрәҗәгать итүчеләрне (вәкилләрне) кабул итү өчен вазыйфаи зат мөрәҗәгать итүченең (вәкилнең) хакыйкый яшәү урынына чыга (бара).

47. Мөрәҗәгать итүче (вәкил) гаризаны электрон рәвештә җибәрә ала, аны рәсмиләштерү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм башка документларны электрон документлар рәвешендә рәсмиләштерү һәм тапшыру тәртибе турында» 2011 елның 7 июлендәге 553 номерлы карары белән билгеләнгән һәм ул гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен, шул исәптән, бер мәгънәле һәм конфиденциаль мәгълүматны җибәрү һәм алу, шул исәптән электрон рәвештә арадаш хәбәрләр һәм җавап мәгълүматы алу мөмкинлеген тәэмин итә торган Бердәм порталны да кертеп, «Интернет» челтәрен кулланып, шул исәптән 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль законда каралган тәртиптә гади электрон имзаны кулланып тапшырыла.

Мөрәҗәгать итүче (вәкил) тарафыннан Бердәм порталны кулланып электрон документ рәвешендә гариза җибәргәндә кулланыла торган электрон имза чаралары 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә сертификацияләнергә тиеш.

48. Вәкаләтле органга Бердәм порталдан файдаланып, электрон документ рәвешендә җибәрелгән гаризаны теркәү, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә (вәкилгә) аның гаризасын алу турында, вәкаләтле органга дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тапшыру датасы күрсәтелгән мәгълүматны үз эченә алган электрон рәвештәге белдерүне формалаштыру һәм җибәрү гариза вәкаләтле органга алынган көнне автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Айлык пособие билгеләү өчен кирәкле документлар билгеләнгән чорда тапшырылмаган очракта, вәкаләтле орган әлеге Административ регламентның 12 пунктында каралган срокта дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында карар кабул итә.

Айлык пособиене билгеләү турындагы гаризаны вәкаләтле органга Бердәм портал аша тапшырган мөрәҗәгать итүче (вәкил) тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар тапшырылган очракта, вазыйфаи зат аларны мөрәҗәгать иткән көнне терки һәм мөрәҗәгать итүчегә (вәкилгә) белдерү бирә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү, аларны рәсмиләштерүнең дөреслеген тикшерү, аларны теркәү, карау, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында карар кабул итү әлеге Административ регламентның 53-68 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

49. Мөрәҗәгать итүчеләргә (вәкилләргә) Бердәм порталда күрсәтелә торган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алу мөмкинлеге тәэмин ителә.

## III. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм чорлары

### Дәүләт хезмәте күрсәткәндә башкарылучы административ процедураларның тулы исемлеге

50. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә

ала:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәүгә алу;

ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында документлар (белешмәләр) таләп итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны карау һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында карар кабул итү;

айлык пособие түләүне оештыру;

түләү эшенә мәгълүмат кертү.

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү буенча административ процедура**

51. Мөрәҗәгать итүченең (вәкилнең) вәкаләтле органга гариза белән шәхсән мөрәҗәгать итүе яисә гаризаның вәкаләтле органга күпфункцияле үзәк аша яисә Бердәм порталны кулланып, электрон документ рәвешендә алынуы административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

Гариза яшәү (тору) урыны буенча яки, расланган яшәү (тору) урыны булмаган очракта – хакыйкый яшәү урыны буенча бирелә.

52. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар вәкаләтле органның вазыйфаи заты тарафыннан кабул ителә.

Күпфункцияле үзәк аша электрон рәвештә якланган элемтә каналлары аша тапшырылган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән расланган булырга тиеш. Шул ук вакытта әлеге гариза һәм документларның кәгазьдәге оригиналлары вәкаләтле органга тапшырылмый.

53. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документларны кабул иткәндә, вазыйфаи зат гаризада күрсәтелгән белешмәләрнең мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документларга, мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларга туры килүен, гариза бланкын тутыру дөреслеген, тапшырылган документларның комплектлылыгын тикшерә.

54. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, вазыйфаи зат әлеге Административ регламентның 15 пунктында каралган чорларда гариза һәм документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү формалаштыра һәм гражданинга бирә, күпфункцияле үзәк аша яисә Бердәм портал ярдәмендә шәхси кабинетка җибәрә.Р298

55. Гаризаны һәм тапшырылган документларны кабул иткәндә вазыйфаи зат әлеге Административ регламентның 32 пунктында каралган чорларда гаризаны гаризаларны һәм вәкаләтле орган карарларын теркәү журналында терки, документларны кабул итү вакытында кире кайтарылырга тиешле документның төп нөсхәләре белән белдерүне рәсмиләштерә һәм мөрәҗәгать итүчегә (вәкилгә) бирә, күпфункцияле үзәк аша тапшыра яки мөрәҗәгать итүчегә (вәкилгә) Бердәм порталдагы шәхси кабинетка җибәрә.Р298

56. Административ процедураның нәтиҗәсе булып дәүләт хезмәте күрсәтү

өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү тора.

57. Административ процедураны үтәү нәтиҗәсен теркәү ысулы булып дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны вәкаләтле органның гаризаларны теркәү журналында теркәү тора.

**Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында документларны (белешмәләрне) соратып алу буенча административ процедура**

58. Административ процедураны башлау өчен әлеге Административ регламентның 24 пунктында каралган документларны (белешмәләрне) соратып алу зарурилыгы нигез булып тора.

Вәкаләтле орган дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында түбәндәгеләр белән үзара хезмәттәшлек итә:

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы;

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы;

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы;

Суд приставлары федераль хезмәте;

Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте;

Федераль салым хезмәте;

Хезмәт һәм мәшгульлек буенча федераль хезмәт;

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте;

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды;

Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органнары.

Әлеге органнарга ведомствоара мәгълүмат сорау турында рәсми мөрәҗәгать ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең региональ системаларын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

59. Вәкаләтле орган, айлык пособие билгеләү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү көненнән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча, әлеге Административ регламентның 24 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле белешмәләрне бирү турында ведомствоара гаризалар формалаштыра һәм җибәрә.

Әлеге Административ регламентның 24 пунктында каралган белешмәләр ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, әлеге Регламентның 24 пунктында каралган белешмәләр әлеге белешмәләрне үз эченә алган документлар белән эш итүче органнар тарафыннан бирелә.

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясының 3 өлеше нигезендә ведомствоара гаризаларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап биш эш көненнән артырга тиеш түгел.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр, сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки аларда булган белешмәләрне) алу.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.

60. Административ процедураның нәтиҗәсе булып, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында соралган мәгълүматларны алу тора.

61. Административ процедураны үтәү нәтиҗәсен теркәү ысулы булып мәгълүмати системага ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында кергән мәгълүматларны кертү тора.

## Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны карау һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында карар кабул итү административ процедурасы

62. Административ процедураны башлау өчен вәкаләтле органга гариза һәм әлеге Административ регламентның 18, 20, 21, 24 пунктларында каралган документлар керү нигез булып тора.

Вазыйфаи зат, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле барлык документлар кергән көннән соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча, гаризаны һәм тапшырылган документларны карый, мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү хокукын билгели һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында карар кабул итә.

Мөрәҗәгать итүче (вәкиле) тарафыннан бирелгән айлык пособие билгеләү турындагы гаризада һәм (яисә) документларда (белешмәләрдә) дөрес булмаган һәм (яисә) тулы булмаган мәгълүмат булуы факты ачыкланган очракта, вәкаләтле орган айлык пособиене билгеләү яисә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү срогын мөрәҗәгать итүче тарафыннан айлык пособиене билгеләү турында эшләп бетерелгән гариза һәм (яки) эшләп бетерелгән документлар (белешмәләр) тапшырылган вакытка кадәр, ләкин 5 эш көненнән артмаган чорга туктатып тора.

Билгеләнгән вакытка ведомствоара электрон багланышлар кысаларында соратып алынган документлар (белешмәләр) алынмаган очракта, яки җитешмәгән документлар (белешмәләр) айлык пособиене билгеләү турындагы гариза теркәлгән көннән соң биш эш көненнән соңрак чорда тапшырылган очракта, вәкаләтле орган айлык пособиене билгеләү яисә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү вакытын 20 эш көненә кадәр озайта.

Әлеге Административ регламентның 14 пунктында каралган айлык пособиене билгеләү яисә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү вакытын туктатып тору, озайту, яңарту вәкаләтле орган карары белән рәсмиләштерелә.

Вәкаләтле органның айлык пособиене билгеләү яисә билгеләүдән баш тарту турындагы карарны кабул итү вакытын туктатып тору, озайту турындагы карары әлеге Административ регламентның 12 пунктындагы беренче абзацында, 13 пунктында, 14 пунктының икенче абзацында каралган чор тәмамлангач бер эш көне эчендә кабул ителә.

Вәкаләтле органның айлык пособиене билгеләү яисә билгеләүдән баш тарту турындагы карарын кабул итү чорын торгызып җибәрү турындагы карары айлык пособиене билгеләү турында эшләп бетерелгән гариза һәм (яки) документлар (белешмәләр) алынганнан соң бер эш көне эчендә кабул ителә.

Вәкаләтле орган мөрәҗәгать итүчегә (вәкилгә) аны җибәрү фактын һәм датасын билгеләргә мөмкинлек бирүче ысул белән айлык пособие билгеләү яисә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү вакытын туктатып тору, озайту, яңарту турында хәбәр итә.

63. Әлеге Административ регламентның 18, 20, 24 пунктларында каралган гаризаларны һәм документларны карау нәтиҗәләре буенча вәкаләтле орган, әлеге Административ регламентның 11 пункты нигезендә, бирелгән гаризага карап, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында карар кабул итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, вәкаләтле орган мөрәҗәгать итүчегә (вәкилгә) карар кабул ителгән көннән бер эш көненнән дә артмаган срокта, аны җибәрү фактын раслау мөмкинлеген тәэмин итә торган ысул белән, кабул ителгән карар турында белдерү җибәрә.

Күпфункцияле үзәк аша гариза биргән очракта, кабул ителгән карар турында белдерү мөрәҗәгать итүчегә (вәкилгә) күпфункцияле үзәк аша җибәрелә.

Гариза электрон рәвештә Бердәм портал аша бирелгән очракта, кабул ителгән карар турында белдерү электрон документ рәвешендә мөрәҗәгать итүчегә (вәкилгә) Бердәм портал аша җибәрелә.

64. Айлык пособие билгеләү турында карар кабул ителгән очракта, вәкаләтле орган айлык пособие күләмен һәм айлык түләүне түли башлау датасын билгели.

65. Административ процедураның нәтиҗәсе һәм административ процедураны үтәү нәтиҗәсен теркәү ысулы булып вәкаләтле орган тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында карар кабул итү тора.

**Айлык пособие түләүне оештыру буенча административ процедура**

66. Вәкаләтле орган тарафыннан айлык пособиене билгеләү турында карар кабул итү административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

Айлык пособиене түләү вакыты һәм тәртибе, шулай ук айлык пособие түләүне туктату нигезләре 2330 номерлы карарда каралган.

Айлык пособиене китерү айлык пособие билгеләү турындагы гаризада, китерү ысулын үзгәртү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән башкарыла.

Вәкаләтле орган айлык пособиене китереп җиткерү өчен китереп җиткерүгә исәпләнгән айлык пособие суммалары турында документ әзерли.

67. Административ процедураның нәтиҗәсе булып айлык пособиене түләүне оештыру тора.

68. Административ процедураны үтәү нәтиҗәсен теркәү ысулы булып, айлык пособиене түләү өчен китерү документларын формалаштыру тора.

## Түләү эшенә мәгълүмат кертү буенча административ процедура

69. Административ процедураны башлау өчен, илтеп җиткерү ысулын үзгәртү турындагы гариза нигезендә, түләү эшенә мәгълүмат кертү зарурилыгы нигез булып тора.

Мөрәҗәгать итүченең түләү эшенә мәгълүмат кертү әлеге Административ регламентның 13 пунктында каралган чорда, илтеп җиткерү ысулын үзгәртү турындагы гариза нигезендә гамәлгә ашырыла.

70. Административ процедураның нәтиҗәсе һәм административ процедураның нәтиҗәсен теркәү ысулы булып, илтеп җиткерү ысулын үзгәртү турында гариза нигезендә түләү эшенә үзгәрешләр кертү тора.

## Административ процедураларны электрон формада, шул исәптән Бердәм порталны һәм сайтны кулланып башкару тәртибе

71. Бердәм портал, сайт аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә (вәкилгә) системада сорала торган белешмәләрне күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы – булган очракта);

иминиятләштерелгән затның аерым шәхси счетның иминият номеры;

телефон номерын;

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Сайт аша алдан язылуны гамәлгә ашырганда мөрәҗәгать итүчегә (вәкилгә) талон-раслама бастырып чыгару мөмкинлеге тудырыла, әгәр мөрәҗәгать итүче (вәкил) электрон почта адресын хәбәр иткән очракта, әлеге адреска, кабул итү көнен, вакытын һәм урынын күрсәтеп, вәкаләтле органга алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Вәкаләтле орган Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән (вәкилдән) башка гамәлләр башкаруны таләп итәргә хокуклы түгел.

72. Мөрәҗәгать итүче (вәкил) тарафыннан гаризаны формалаштыру, гаризаны

өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Гаризаны формалаштырганда мөрәҗәгать итүче (вәкил) өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә:

гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

гражданинның ихтыярына карап, шул исәптән гаризаның электрон формасына ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон гариза формасына элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

гаризаның электрон рәвешендәге кырларны гражданин тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмат-технологик багланышын тәэмин итә торган инфраструктурада бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2011 елның 28 ноябрендәге 977 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмат-технологик багланышын тәэмин итә торган инфраструктурада бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – бердәм идентификация һәм аутентификация системасы) урнаштырылган белешмәләрне һәм Бердәм порталда, вәкаләтле орган сайтында урнаштырылган белешмәләрне бердәм идентификация һәм аутентификация системасында булмаган белешмәләргә кагыла торган өлешендә файдаланып, белешмәләр кертә башлаганчы ук тутыру;

элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон гариза формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

мөрәҗәгать итүченең (вәкилнең) Бердәм порталда «Шәхси кабинет»та элек бирелгән гаризаларны бер елдан да ким булмаган, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризаларны – кимендә 3 ай эчендә карау мөмкинлеге.

Формалаштырылган гарызига формат-мантыйкый тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә, гарызнамәдә электрон форманың һәр кырын мөрәҗәгать итүче тарафыннан тутыру барышында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Бердәм порталда гаризаның электрон формасындагы кырларның төгәлсезлекләр белән тутырылган булуы ачыкланган очракта, турыдан-туры гаризаның электрон формасында мәгълүмат җиткерү юлы белән, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.

Формалаштырылган гариза вәкаләтле органга Бердәм портал аша җибәрелә.

Бердәм порталны кулланып, электрон документ формасында гариза биргән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү көне булып, Бердәм порталны кулланып, электрон документ формасында гариза бирү датасы санала.

73. Вәкаләтле орган гаризаны кабул итү һәм теркәүне әлеге Административ регламентның 48 пунктында күрсәтелгән срокта, кәгазьдә кабат тапшыру зарурлыгыннан башка гына тәэмин итә.

Теркәлгәннән соң гариза дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы структур бүлекчәгә җибәрелә.

74. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә (вәкилгә) тиешле административ процедураны үтәү тәмамланганнан соң 1 эш көненнән дә артмаган срокта, электрон почта адресына яисә мөрәҗәгать итүче (вәкил) теләге буенча Бердәм портал чараларын кулланып җибәрелә.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең (вәкилнең) электрон почтасына түбәндәгеләр җибәрелә:

гаризаны кабул итү һәм теркәү турында белдерү;

дәүләт хезмәте күрсәтү процедурасының башлануы турында белдерү;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында белдерү.

Бердәм порталда дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат бирү тиешле статусларны мөрәҗәгать итүченең (вәкилнең) шәхси кабинетына җибәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

75. Мөрәҗәгать итүчегә (вәкилгә) әлеге Административ регламентның 83 пункты нигезендә Бердәм порталда дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемлелеген һәм сыйфатын бәяләү мөмкинлеге тәэмин ителә.

**Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү тәртибе**

76. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә документлар бирүне күздә тотмаганга күрә, гамәлгә ашырылмый.

## IV. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

**Вәкаләтле органның җаваплы вазыйфаи затлары тарафыннан Административ регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәтен башкаруга таләпләрне билгеләүче башка норматив хокукый актларның үтәлешен һәм үтәлешен, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы тикшерүне гамәлгә ашыру тәртибе**

77. Вазыйфаи затларның әлеге Административ регламетның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актларның нигезләмәләрен саклавына һәм үтәвенә, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүгә агымдагы контрольлек (алга таба – агымдагы контрольлек) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган структур бүлекчә җитәкчесе, шулай ук вәкаләтле орган җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контрольлек вәкаләтле органның гаризаларны һәм карарларны исәпкә алу журналы мәгълүматлары буенча даими (эш көне нәтиҗәләре буенча) башкарыла.

**Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуына планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздыру тәртибе һәм аларның ешлыгы, шул**

**исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуына контрольлек тәртибе һәм формалары**

78. Вәкаләтле органның вазыйфаи заты тарафыннан әлеге Административ регламент нигезләмәләрен, дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларны үтәүне һәм башкаруны контрольдә тотуны гамәлгә ашыру (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору) максатларында органнар дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгына һәм сыйфатына карата тикшерү (алга таба – тикшерү) үткәрергә мөмкин.

Тикшерүләр актлар һәм боеру документлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

79. Тикшерүләр планлы (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин.

Планлы тикшерүләр өч елга бер тапкыр үткәрелә.

Планнан тыш тикшерүләр хокук саклау һәм башка вәкаләтле дәүләт органнары йөкләмәсе буенча үткәрелә. Тикшерү шулай ук мөрәҗәгать итүченең (вәкилнең) конкрет мөрәҗәгате буенча да үткәрелергә мөмкин.

Планлы тикшерүләр түбәндәге юнәлешләр буенча гамәлгә ашырыла:

дәүләт хезмәте күрсәтү эшен оештыру;

дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфаты;

агымдагы контрольне гамәлгә ашыру.

Тикшерүләр шулай ук тематик характерда булырга мөмкин.

Тикшерү вакытында дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле барлык мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Тикшерүләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә хокук бозуларны ачыклау һәм бетерү максатыннан үткәрелә.

**Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында алар тарафыннан кабул ителә торган (гамәлгә ашырыла торган) карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен вазыйфаи затларның җаваплылыгы**

80. Вазыйфаи зат дәүләт хезмәте күрсәтү чорларын һәм тәртибен үтәү өчен шәхсән җаваплы булып тора.

Вазыйфаи затның шәхсән җаваплылыгы аның вазыйфаи күрсәтмәсендә Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә билгеләнә.

81. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тотучы затлар исемлеге вәкаләтле органның эчке эш итү документлары (боерыклары) белән билгеләнә.

**Дәүләт хезмәте күрсәтүне, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан да, контрольдә тоту тәртибенә һәм формаларына карата таләпләр**

82. Вәкаләтле орган дәүләт хезмәте күрсәтүне даими контрольдә тота.

Вәкаләтле орган тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләренә анализ ясала, аның нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүне оештыруда җитешсезлекләрне бетерү буенча кирәкле чаралар күрелә.

83. Гражданнар (берләшмәләр, оешмалар) ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль башкарма хакимият органнарының (аларның структур бүлекчәләре) территориаль органнары һәм бюджеттан тыш дәүләт фондларының (аларның төбәк бүлекләре) территориаль органнары җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру сыйфатын исәпкә алып, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында, шулай ук әлеге бәяләү нәтиҗәләрен тиешле җитәкчеләрнең үз вазыйфаи бурычларын үтәүне вакытыннан алда туктату турында карарлар кабул итү өчен нигез буларак кабул итү турында» 2012 елның 12 декабрендәге 1284 номерлы карарында каралган тәртиптә һәм рәвешләрдә гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә (вәкилгә) дәүләт хезмәте күрсәткәндә вәкаләтле органның вазыйфаи заты (күпфункцияле үзәкнең хезмәткәре) аңа күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең сыйфаты турында гражданнардан фикерләр җыелуы турында мәгълүмат җиткерә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләүдә катнашу өчен күчмә ридотелефон элемтәсе җайланмасының абонент номерын бирергә (яки «Интернет» челтәрендә аңа күрсәтелгән дәүләт хезмәтен бәяләргә) тәкъдим итә.

Мөрәҗәгать итүче (вәкил) күчмә радиотелефон элемтәсе чараларыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләүдән баш тарткан очракта, вазыйфаи зат әлеге бәяләүдә катнашу өчен терминал яки дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен бирү урынында турыдан-туры урнашкан бүтән җайланмадан файдаланып (техник мөмкинлекләр булган очракта) бәяләргә, яки аңа күрсәтелгән дәүләт хезмәте сыйфатын Интернет челтәрендәге махсус сайтта («Ваш контроль»), шулай ук Бердәм порталда «Шәхси кабинет»та бәяләргә тәкъдим итә.

Мөрәҗәгать итүче (вәкил) күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмасы ярдәмендә дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләүдә катнашырга ризалык белдергән очракта, мөрәҗәгать итүче (вәкил) күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмасының абонент номерын бирә, ул дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфаты турында аның фикерен ачыклау өчен кирәкле белешмәләр белән бергә «Дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатын мониторинглауның мәгълүмати-аналитик системасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасына тапшырыла, аның турында нигезләмә Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт хезмәтләре сыйфатын мониторинглауның мәгълүмати-аналитик системасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы турында нигезләмә раслау хакында» 2013 елның 1 мартындагы 114 номерлы боерыгы белән расланган.

## V. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган вәкаләтле орган, күпфункцияле үзәк, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

**Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителгән гамәлләргә**

**(гамәл кылмауга) һәм (яисә) кабул ителгән (гамәлгә ашырылган) карарларга мөрәҗәгать итүчеләрнең (вәкилләрнең) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү хокукы турында мәгълүмат**

84. Мөрәҗәгать итүче (вәкил) вәкаләтле органнарның, аларның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять (алга таба – шикаять) бирү хокукына ия.

**Мөрәҗәгать итүченең шикаятен судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә карауга вәкаләтле дәүләт хакимияте органнары, оешмалар һәм шикаятьне карап тикшерүгә вәкаләтле затлар**

85. Судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә мөрәҗәгать итүче (вәкил) шикаять белән кәгазьдә яисә электрон формада вәкаләтле органга, күпфункцияле үзәккә яисә күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы (алга таба – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы) гавами-хокукый берәмлекнең тиешле дәүләт хакимияте органына (җирле үзидарә органына) вәкаләтле органның карарына һәм (яки) гамәленә (гамәл кылмавына) карата мөрәҗәгать итәргә хокуклы;

вәкаләтле орган җитәкчесенә – вәкаләтле органның вазыйфаи заты карарына һәм (яисә) гамәленә (гамәл кылмавына) карата;

күпфункцияле үзәк җитәкчесенә – күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына);

күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга яисә Татарстан Республикасының норматив хокукый акты белән вәкаләт бирелгән вазыйфаи затка, – күпфункцияле үзәк карарына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата.

**Шикаятьне бирү һәм карау тәртибе турында, шул исәптән Бердәм порталдан файдаланып, мөрәҗәгать итүчеләргә (вәкилләргә) хәбәр итү ысуллары**

86. Шикаятьне бирү һәм карау тәртибе турындагы мәгълүмат дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннардагы мәгълүмат стендларында, сайтта, Бердәм порталда урнаштырыла, шулай ук телефон буенча һәм (яки) шәхсән кабул иткәндә телдән җиткерелә яисә мөрәҗәгать итүче (вәкил) тарафыннан күрсәтелгән почта адресы буенча язмача яки электрон хәбәр рәвешендә җибәрелә.

**Дәүләт хезмәте күрсәтүче вәкаләтле орган, шулай ук аның вазыйфаи затлары карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибен җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге**

87. Вәкаләтле органның, шулай ук аның вазыйфаи затлары карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе түбәндәгеләр белән җайга салына:

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон;

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль закон;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль башкарма хакимият органнарының һәм аларның вазыйфаи затларының, федераль дәүләт хезмәткәрләренең, Россия Федерациясе бюджетныкы булмаган дәүләт фондлары вазыйфаи затларының, билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча федераль законнар нигезендә вәкаләт бирелгән дәүләт корпорацияләренең һәм аларның вазыйфаи затларының, «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә каралган оешмаларның һәм аларның хезмәткәрләренең, шулай ук дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрнең һәм аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр тапшыру һәм аларны карау тәртибе турында» 2012 елның 16 августындагы 840 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә гамәлгә ашырылган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2012 елның 20 ноябрендәге 1198 номерлы карары.

88. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында органнар, аларның вазыйфаи затлары, күпфункцияле үзәкләр, шулай ук күпфункцияле үзәкләр хезмәткәрләре тарафыннан кабул ителгән гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм (яки) карарларга мөрәҗәгать итүчеләрнең (вәкилләрнең) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү хокукы турында, судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә җибәрелгән шикаятьне карауга вәкаләтле булган органнар, оешмалар һәм затлар, мөрәҗәгать итүчеләргә (вәкилләргә) шикаятьне тапшыру һәм аны карау тәртибе турында, шул исәптән Бердәм порталны кулланып, шулай ук органнарның, аларның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкләрнең, шулай ук күпфункцияле үзәкләр хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат мәҗбүри рәвештә Бердәм порталда урнаштырылырга тиеш.

## VI. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

### Күпфункцияле үзәкләр башкара торган административ процедураларның (гамәлләрнең) тулы исемлеге

89. Күпфункцияле үзәк тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

гражданнарга күпфункцияле үзәктә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы, дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле башка мәсьәләләр буенча мәгълүмат бирү, шулай ук күпфункцияле үзәктә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында гражданнарга консультация бирү;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гражданнардан гариза алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итү;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарга, дәүләт хакимиятенең башка органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм дәүләт хезмәтләрен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга күпфункцияле үзәк тарафыннан ведомствоара гариза формалаштыру һәм җибәрү;

гражданга дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча күпфункцияле үзәккә җибәрелгән электрон документларның эчтәлеген раслый торган кәгазьдә документлар бирү, шулай ук кәгазьдә документларны, шул исәптән дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның мәгълүмат системаларыннан өземтәләрне һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнардан өземтәләрне дә кертеп, бирү.

**Гражданинга күпфункцияле үзәктә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны үтәү барышы, дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле башка мәсьәләләр буенча мәгълүмат бирү, шулай ук күпфункцияле үзәктә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында гражданнарга консультация бирү буенча административ процедура**

90. Күпфункцияле үзәктә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы яки дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларның әзерлеге турында гражданинга хәбәр итү түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

гражданнарны шәхси кабул итү барышында;

телефон аша;

электрон почта аша.

91. Гражданин күпфункцияле үзәккә электрон почта аша дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, күпфункцияле үзәк әлеге гариза күпфункцияле үзәккә алынган көннән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча гражданинга җавап җибәрә.

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документлар һәм дәүләт хезмәте күрсәтү турында гражданинның күпфункцияле үзәк тарафыннан гаризасын кабул итү буенча административ процедура**

92. Административ процедураны башлау өчен гражданинның дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар белән Россия Федерациясе территориясе чикләрендә, гражданин ихтыярына карап, аның яшәү урынына, тору урынына, хакыйкый яшәү урынына яисә түләү эше урнашкан урынына бәйсез рәвештә теләсә кайсы күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать итүе нигез булып тора, әгәр дәүләт хезмәтен күрсәтә торган вәкаләтле орган һәм күпфункцияле үзәк арасында үзара хезмәттәшлек турында килешү төзелгән булса һәм әлеге гаризаны тапшыру күпфункцияле үзәктә күрсәтелә торган, килешүдә каралган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлегендә каралган булса.

Гражданнар дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать итү юлы белән, вәкил аша мөрәҗәгать итә алалар.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү көне дип күпфункцияле үзәк тарафыннан гаризаны кабул итү көне санала.

93. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган Күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрендә каралган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтү таләпләрен исәпкә алып, гариза, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле белешмәләр, документлар һәм мәгълүмат вәкаләтле орган тарафыннан күпфункцияле үзәктән якланган элемтә каналлары буенча көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән расланган электрон рәвештә алынырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза һәм документларның кәгазьдәге оригиналлары вәкаләтле органга тапшырылмый.

94. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе гражданинның теләге буенча көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон формада, гражданин тарафыннан гаризаны формалаштырганда күрсәтелгән электрон почта адресына таләп ителгән урын буенча җибәрелә ала.

## Дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарга, дәүләт хакимиятенең башка органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм дәүләт хезмәтләрен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга күпфункцияле үзәк тарафыннан ведомствоара гариза формалаштыру һәм җибәрү административ процедурасы

95. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә күпфункцияле үзәк тарафыннан ведомствоара гариза формалаштыру һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнарга, дәүләт хакимиятенең башка органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмаларга җибәрү гамәлгә ашырылмый.

## Гражданинга дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча күпфункцияле үзәккә җибәрелгән электрон документларның эчтәлеген раслый торган кәгазьдә документлар бирү, шулай ук кәгазьдә документларны, шул исәптән дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның мәгълүмат системаларыннан өземтәләрне һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнардан өземтәләрне дә кертеп, бирү административ процедурасы

96. Гражданин белешмәләр сорап мөрәҗәгать иткән очракта, күпфункцияле үзәк хезмәткәре ведомствоара электрон багланышлар системасы аша ведомствоара гариза формалаштыра һәм реаль вакыт режимында җавап ала. Алынган мәгълүматларны бастыра, күпфункцияле үзәкнең штампын һәм мөһерен, тулы имзасын күрсәтеп, имза белән таныклый. Белешмәләрне гражданинга (гражданинның вәкиленә) тапшыра.